**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ ВЕРХНЕКАМЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
улица Дружба, дом 1а, село Верхняя Каменка, 423108

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ЮГАРЫ КӘМИНКӘ АВЫЛ СОВЕТЫ**
Дружба урамы, 1а йорт, Югары Кәминкә авылы, 423108

тел./факс (84396) 2-31-60/2-34-16 email: Vkam.Cmn2@tatar.ru

19 сентябрь 2019 ел № 120

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮГАРЫ КӘМИНКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ КАРАРЫ

Югары Кәминкә авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрү турында

2002 елның 12 июнендәге 67 – ФЗ номерлы «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22,56 статьялары, «Җирле референдум турында " 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Югары Кәминкә авыл җирлеге Уставы нигезендә, Югары Кәминкә авыл җирлеге Башкарма комитетының 2009 елның 19 сентябрендә кабул ителгән 119 номерлы «Референдум үткәрү инициативасы турында» карарын карап тикшергәннән соң Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Югары Кәминкә авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. 2019 елның 17 ноябренә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга: Мәсьәлә буенча җирле референдум үткәрүне башлап җибәрергә: “Килешәсезме 2020 елда көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүче гражданнар, 1 төркем инвалидлардан тыш Югары Кәминкә авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлтү турында:

- Югары Кәминкә, Ибрай Каргалы, Кызыл Яр торак пунктларында урам утларын монтажлау, урнаштыру, ремонтлау, карап тоту һәм хезмәт күрсәтү, кулланылган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу (хезмәтләр күрсәтү);

- урам су челтәрен һәм су башняларын ремонтлау (артезиан скважинасы территориясенең санитар-саклау зонасын төзекләндерү, коймаларны ремонтлау һәм буяу, су башняларын буяу, насос һәм автоматиканы алыштыру);
- җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерүгә, карап тотуга, хезмәт күрсәтүгә чыгымнар (юл кырыйларын чабуга, юлларны грейдерлауга, урамнарны кардан чистартуга, ягулык-майлау материаллары сатып алуга, тракторчыга түләү, запас частьләр сатып алуга), югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар сатып алуга (хезмәтләр күрсәтүгә);
- ротор чапкыч сатып алу;
- авыл җирлеге урам-юл челтәрен норматив хәлгә китерү (вак таш җәю);
- Кызыл Яр авылы зиратын төзекләндерү, агачлар кисү, коймаларны ремонтлау, буяу, югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу (хезмәтләр күрсәтү);
- Ибрай Каргалы, Кызыл Яр торак пунктларында хәбәр итү системасын сатып алу һәм урнаштыру

ӘЙЕ ЮК»

3. Әлеге карарны "Безнең Чирмешән" район газетасында ("Наш Черемшан") бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталына (pravo.tatarstan.ru) Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Башлык, Югары Кәминкә
авыл җирлеге Советы рәисе К. М. Гыйләҗев